**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

30.06.2021 № 196

**2021–2022 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы боерыгы белән расланган электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яисә) өлешчә чикләү кагыйдәләренең 15, $15^1$ пунктлары нигезендә:

1. 2021–2022 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучыларның кушымтада бирелгән исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Президентының «2020–2021 еллар чорына алар тарафыннан электр энергиясен куллану режимын чикләү икътисадый, экологик, социаль нәтиҗәләргә китерүе мөмкин булган электр энергиясен (куәтен) кулланучылар исемлеген раслау турында» 2020 елның 30 июнендәге 208 номерлы боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**